**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау тиемер юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13

**СОВЕТ КРАСНОСЕЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422700, Республика Татарстан, Высокогорский район,
п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82,e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**
**18 июль 2022 г.** **№ 49**

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектын гамәлдән чыгару хакында**

Федераль һәм региональ законнардагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советының 2019 елның 12 декабрендәге 152 нче номерлы карары белән кабул ителгән (Советның 2020 елның 11 августындагы 172 нче номерлы, 2021 елның 15 гыйнварендагы 15 нче номерлы карарлары редакциясендә) «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы проектын әзерләү максатларында, әлеге үзгәрешләрне исәпкә алып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28, 44 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7, 20 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Красносельский авыл җирлеге Советының 2021 елның 9 октябрендәге 33 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты хакында» карарын гамәлдән чыгарырга.
2. Красносельский авыл җирлеге Советының 2021 елның 9 октябрендәге 33 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты хакында» карары нигезендә 2021 елның 28 октябрендәге 9.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау тимер юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13 нче йорт адресы буенча үткәрелгән гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен гамәлдән чыгарырга.
3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советының 2019 елның 12 декабрендәге 152 нче номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» (Советның 2020 елның 11 августындагы 172 нче

номерлы, 2021 елның 15 гыйнварендагы 15 нче номерлы карарлары редакциясендә) проектын, федераль һәм региональ законнардагы соңгы үзгәрешләрне исәпкә алып эшләргә.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Красносельский авыл җирлеге
Башлыгы урынбасары Р.Р. Никитенко